РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 54 2020 елның 29 июне

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маенда кабул ителгән 42 номерлы «Муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә торган өстәмә ташламалар исемлеге турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р һәм 821-р номерлы күрсәтмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 20 маенда кабул ителгән 42 номерлы «Муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә торган өстәмә ташламалар исемлеге турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә торган өстәмә ташламалар исемлегенең 1 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләре түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаган арендага алучылар – кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен кичектереп тору бирелә».

1.2. муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә торган өстәмә ташламалар исемлегенең 2 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә әлеге исемлекнең 2 пунктындагы 1 абзацында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләре түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаган арендага алучыларга карата гамәлгә ашырыла».

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль<br>районы Башлыгы | ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН / ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН | А.Р.Метшин